ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитетының 2019 елның сентябреннән 2023 елның декабренә кадәр чордагы эше турында хисабы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитетының 2019 елның сентябреннән 2023 елның декабренә кадәр чордагы эше турында хисабын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. Эшчәнлеге юнәлешләре буенча Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатлары, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советының һәм Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасының профильле комитетлары, Россия Федерациясе субъектларының закон чыгару органнары комитетлары (комиссияләре) белән хезмәттәшлек эшен дәвам итәргә.

2.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативаларын һәм мөрәҗәгатьләрен карауны контрольдә тоту өлешендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы, Россия Федерациясе Хөкүмәте белән хезмәттәшлекне арттырырга.

2.3. Татарстан Республикасы законнарын үз вакытында актуальләштерү максатында аларга мониторинг үткәрүне дәвам итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 18 декабре
№ 2304-VI ДС